

Октябрь революциясенең берьеллыгын бәйрәм итү. Шәһәр театры каршындагы митинг. Татарстан республикасы тарихи-сәяси документлар үзәк дәүләт архивы, фотодокументлар коллекциясе, инв. № 477.

Октябрь революциясендә татарлар

Революцияләр турында күп язган булсам да, бу темага кабат әйләнеп кайтам. Беренчедән, 1917 елгы Октябрь революциясенең 90 еллыгы килеп җитте. Икенчедән, бүгенге көндә аңа карата тискәре карашлар гына хөкем сөрә. Аны күрмәмешкә сабышу гамәлләре дә ярылып ята.

90 ел элек булып үткән вакыйгаларның шаһиты — америкалы журналист Джон Рид инкыйлаб көннәрен «дөньяны тетрәткән ун көн» дип бәяләгән иде. Чөнки ул Россияне генә түгел, гомумән, кешелек дөньясының астын өскә китерде. Колониаль империяләр юкка чыкты, алар урынында бәйсез дәүләт-

ләр туды һәм башка бик күп позитив үзгәрешләр хасил булды.

Россия империясе урынына аның эчендә республикалар төзелү рәвешендә СССР барлыкка килде. Тар хокуклы, җире шактый кысрыкланган рәвештә булса да, Татарстан автономияле республикасы да калкып чыкты. Әгәр дә шул вакыт республика төзелмәгән булса, бүген аны барлыкка китерү мөмкин булыр идеме? Бер нинди суверенлык декларациясе дә, референдум да, Россия белән шартнамә төзү дә мөмкин булмас иде.

Дөрес, революция халкыбызга зур афәтләр дә китерде. Моны бер кем дә инкарь итә алмас. Очсыз-кырыйсыз репрессияләр, эзәрлекләүләр, сугыш афәте милләтебезнең яшәешенә, телебезгә, динебезгә зур зарарлар китерүен һич тә онытырга ярамый. Дөньяда булган бер генә революцияне дә бер яклы гына бәяләү мөмкин түгел. Алар, бер яктан, яшәешнең бер этәргече булсалар, икенче яктан, халыкларга бик күп зыян да китергәннәр. Заманында Англия һәм Франциядә булып үткән революцияләр тарихы шуны күрсәтә. Октябрь революциясе шулай ук чыгарма түгел.

Ләкин революцияләр бер кайчан да сәбәпсез килеп чыкмыйлар. Аларның төп сәбәбе — халыкның күпчелеге искечә яши алмауга кайтып кала. Россиядәге 1905-1907 һәм 1917 елгы революцияләрнең дә сәбәпләре шул ук. Халыкның күпчелеге искечә яшәргә теләми, радикаль үзгәрешләр таләп итә. Россия өчен уңышсыз дәвам иткән Бөтендөнья сугышы халыкның хәлен түзә алмаслык дәрәҗәгә җиткерә. Патша һәм аның хөкүмәте ил белән идарә итә алмаслык хәлдә булалар. Революцион ситуация барлыкка килеп, башта патшаны, ә аннан соң хәтта Вакытлы хөкүмәтне дә үлемгә дучар итә. Болары турында күп язылды. Тик менә революциянең милли төсмеренә әлегәчә тулы бәя бирелгәне юк. Чыннан да, ни өчен бу революцияләрдә рус булмаган халыклар күпләп катнаша? Анда татарлар ни өчен күтәрелгән? Менә бу сорау бүген дә күпләрне борчый.

Моңа җавап эзләгәндә, татарларның XX гасыр башында яңарыш кичереп, яңача яшәү рәвешенә күчеп килүче милләт булганлыгын онытырга ярамый. Татар дистәләгән газета-журнал, ел саен бик күп тиражлы йөзләгән китап чыгарып килгән халык. Ул газета-журналларны үз арасында гына түгел, башка милләтләргә дә җиткерә. Үз мөмкинлекләренә көйләнгән мәктәп системасы булдыра һәм Россиянең иң мәгърифәтле милләтенә әверелә. Тик менә милләтнең мәгарифе, мәдәнияте иске жандарм кысаларына җайланган системага сыймый. Аның күпкырлы эшчәнлеге контроль астында тора. Дистәләгән милләтпәрвәрләр сөрген-каторгаларда иза чигә. Татар моңа риза була алмаган, әлбәттә.

Татар халкының күпчелеге авылда яшәгән, җирсезлектән интеккән. Аларның җире русларныкы белән чагыштырганда 1,5-2 мәртәбәгә азрак булган. Татар халкының тик 3 % гына 12 дисәтинәдән артыграк җиргә ия булган. Шунлыктан, татар крестьяннары руслар белән бергә аграр хәрәкәттә катнашып килгәннәр. Җирсезлек татарларны төп җирләрен ташлап, башка якларга бәхет эзләп китәргә мәҗбүр иткән. Россиянең төрле төбәкләрендәге завод-фабрикаларда да, Донбасс, Урал, Себер шахталарында да милләттәшләребезнең саны шактый булган. Һәм алар да эшчеләр хәрәкәтендә актив катнашканнар.

Ләкин татар эшче, крестьян, фабрикант яки завод хуҗасы булса да, татарлыгын һәм, бигрәк тә, динен саклап килгән. Аның милли аңы сыйнфыйлыкка үрелеп барган. Татарны сыйнфыйлык бүлгәләсә дә, милли аң ниндидер рәвештә булса да, аның барлык катламнарында да бердәмлек хисләрен саклап килгән. Революциянең бер үзенчәлеге шунда ки, ул тирәнәя барган саен сыйнфыйлыкны беренче урынга чыгара.

Патша бәреп төшерелгәннән соң татарлар арасында да таркалу көчәя. «Без хәзер көннән-көн аерылабыз, крестьяннар рус крестьяннары белән бергә бара. Эшчеләребез рус эшчеләреннән, әлбәттә, аерылмый, кайсыбыз социал-демократ булдык, кайсыбыз социалист-революционерларга язылды, беребез милләтче, икенчебез милләтне инкарь итә... Халык аерылды, электән дә юк дәрәҗәсендәге аз көчләребез хәзер бөтенләй таркалды», — дип ачынып язган социалист Ф. Туктаров[1].

Мәсьәләнең катлаулыгы социалистларның үз араларында бердәмлек булмауда. М. Вахитов тарафыннан тө-

зелгән Мөселман социалистлар комитетында большевиклар да, меньшевиклар да, эсерлар да була. Ләкин комитеттагыларның күпчелеге сыйнфыйлыкны беренче урынга чыгара. Ф. Туктаров та шушы оешмада булуына карамастан, М. Вахитовтан аермалы буларак, миллилекне беренче урынга куя. Әйтик, ул 1917 елның 2 июлендә үзе чыгарган «Корылтай» газетасының баш мәкаләсендә татарлар алдында торган бурычларны ачыкларга тырыша. Аның фикеренчә, шушы бурычларның нигез ташы булып, нинди дә булса партиячелек принцибыннан баш тарту тора. Ул бигрәк тә большевикларны нык тәнкыйтьли. Ул аларны «энә очыдай» бер партия, дип атый: «Безнең дә, үзебезгә күрә, большевик дигән партиябез бар, алар да бүген үк Русия татарлары арасында социализм кертмәкче булалар. Бездә дә, үзенә күрә, анархия-башбаштаклык башланып бара»[2]. Шул ук вакытта автор татар байлары һәм алпавытларының милли эшләрдән читләшүен дә күрсәтеп үтә. Ул революциянең теләсә нинди очракта да русларга файдалы булачагына басым ясап, татарның бер нәрсәсез калу ихтималын кисәтә. «Без хаким милләт түгел, бездә байлык та, гыйлем дә, мәгариф тә, мәдәният тә юк. Без зәгыйфь, сырхау, әлегә кадәр кол булып, изелеп яшәгән бер халык бит», — дип яза ул[3]. Газетасының бер санында Ф. Туктаров Россиядәге сәяси хәрәкәтне өч агымга: кадет, гомумсоциалистик юнәлеш, большевизмга бүлеп күрсәтә һәм аларга булган мөнәсәбәтен түбәндәге рәвештә билгели: «Русиянең шул хәленә, шул өч агымына, тартышына без төрки-татарларның мөнәсәбәте ничек соң? Без, әлбәттә, кадетлар белән бергә бара алмыйбыз. Әя — Суфиягә дип ясаган түр тәреләрен без күтәрешеп бара алмыйбыз инде, аңа безнең көчебез җитми, кулыбыз күтәрелми. Без, әлбәттә, большевиклар да була алмыйбыз. Бездә бүгеннән үк социализм кертерлек гыйлем юк әле. Без социализм түгел, республика сүзен дә быел гына ишеттек, капитал дигән сүзне дә хәзер генә өйрәнергә тотынмакчы булабыз әле. Без әле социальный революцияне генә түгел, хәзер ясалып килә торган сәяси революцияне дә көчкә-көчкә генә аңлыйбыз. Аңа да хәзерләнеп куя алмаганбыз. Без большевиклар белән бергә бара алмыйбыз. Бара алмыйбыз гына түгел, хәтта арабызда большевик булган, йә большевик фикерен тарата торган халык безнең милләтебезгә, төркилегебезгә... зарар итәчәк»[4].

Шул ук вакытта автор рус халкына дустанә мөнәсәбәт, ә Вакытлы хөкүмәткә үпкәсен дә белдерә: «Мөселманнар рус халкы белән әлегә кадәр бергә булдылар, мәмләкәтне бергә сакладылар, тик хөкүмәт үзе генә безне какмасын, безнең дә дөньяда барлыгыбызны, бар булырга, яшәргә теләгәнебезне онытмасын»[5].

Тик, Ф. Туктаров кебекләрнең тырышуларына да карамастан, 1917 ел татар яшәешенә сыйнфыйлык принцибын ныклап урнаштыра. Татарлар яз һәм җәй айларындагы эшчеләр забастовкаларында, крестьяннар хәрәкәтендә, армия сафларындагы солдат оешмаларының эшчәнлегендә ныклап катнашалар. Ләкин татар икәнлекләрен онытмыйлар. Киресенчә, ил буенча йөзләгән мөселман оешмасы туа. Алар милли агарту эшен киң җәелдереп җибәрәләр. Армиядә мөселман частьләре барлыкка килә. Хәтта милли корпус та оештырыла башлый. Бу хәл халыкның күпчелеге революциягә, бигрәк тә радикаль таләпләр куйган сул партияләргә өмет баглаганлыгы турында сөйли.

Октябрь көннәре якынлашкач, инде канлы бәрелешнең булачагы ачыклангач, Бөтенроссия хәрби шурасы татар солдатларын анда катнашмаска өнди. «Менә шундый кара көннәргә ирешмәс өчен без Советлар белән армиянең тавышына колак салырга һәм большевиклар тарафыннан булачак выступлениегә бар көчебез белән каршы торырга тиешбез», — дип яза «Безнең тавыш» газетасы[6]. Ләкин фактлар татар солдатларының бу өндәүгә колак салмаганлыкларын күрсәтә. «Алар төннәрен ач килеш, большевиклар белән сугыштылар, байтак кына авырлыкларга очрадылар», — дип уфтанучылар да була[7].

Дөрес, чуалышларда барлык халык катнашты дип уйлау зур хата булыр иде. Казан вакыйгалары, гомумән, юнкерлар һәм солдатлар арасындагы бәрелеш кенә итеп саналырга тиеш. Аларга хәтта элеккеләре белән чагыштырганда, тулы сәяси төс бирү дә бик урынлы булмас иде. 24 октябрь кичен Казан советының солдат секциясе председателе



Казанда Октябрь революциясенең берьеллыгы. Хәрби парад. Татарстан республикасы тарихи-сәяси документлар үзәк дәүләт архивы, фотодокументлар коллекциясе, инв. № 475.

Н. Ершов тәкъдиме белән гарнизонда булган, 1889 елда хәрби хезмәткә чакырылган солдатларны өйләренә кайтарып җибәрү хакында карар кабул итә. Хәрби округ командованиесе моңа җавап итеп Н. Ершовны һәм Казан большевиклар оешмасының җитәкчесе К. Грасисны кулга алу өчен юнкерлар җибәрә. Ләкин солдатлар Н. Ершовны юнкерларга бирмиләр. Гарнизонда атышлар башлана. Шуннан соң гына вакыйгаларга акрынлап сәяси төс керә башлый. Бу урында бер уйдырманы фаш итү урынлы саныйм.

1934 елдан башлап тарих китапларына беренче буларак «Очерки истории Татарской партийной организации» исемле китапта Казандагы кораллы восстание Петроградтан РСДРП(б) Үзәк Комитетыннан алынган күрсәтмә нигезендә башланды дигән раслама кереп урнаша. Имеш, 23 октябрь кичендә Казан большевиклар оешмасының комитет утырышы булып, Үзәк Комитетның күрсәтмәсе укыла һәм шуның нигезендә кораллы восстание үткәрү турында карар кабул ителә. Чынлыкта, Петроградтан бернинди күрсәтмә дә килми, әйтеп үтелгән утырыш та булмый, карар да кабул ителми. Комитет әгъзалары өчен гарнизонда башланган вакыйгалар бөтенләй көтелмәгән хәл була. Бу вакыйгалардан соң өч көн үткәч, 30 октябрь көнне РСДРП(б) комитетының утырышында аларга анализ ясала. Анда рәислек кылган А. Карпов: «Соңгы көннәрдәге вакыйгалар Петроградтагы власть алмашынуы турындагы хәбәр алынганчы ук башланды һәм аларга комитет түгел, ә аның аерым әгъзалары җитәкчелек итте» — дип белдерә. Комитетның тагын бер әгъзасы И. Мохов үзенең истәлекләрендә «комитет өчен кабынып киткән бәрелеш көтелмәгән хәл булды», — дип яза. Димәк, 1917 елның октябрендәге Казан вакыйгалары, нигездә, хәрби гарнизон белән генә чикләнгән. Һәм анда эшчеләр, шул исәптән татар эшчеләре дә, актив катнашмаган. Аңа сәяси төс бирергә омтылу большевикларның җитәкчелек ролен күрсәтергә тырышу максатыннан килеп чыккан.

Башланып киткән вакыйгалар большевиклар комитеты өчен дә көтелмәгән хәл булган, гади халык өчен баштарак ул бер уен кебек кенә кабул ителгән. Әле күпләр шул уеннан уймак чыгасын хәтта чамалый да алмаганнар. Газеталардагы материалларга караганда, шәһәр халкының күпчелеге атышларны читтән генә, спектакль карагандай күзәтеп торган. «Сугыш мәйданы» Академический слободада булганга күрә, шул тарафтан атылган туп вә шрапнельләрдән шәһәрнең урта ягы гына зарарланган. Шәһәрнең мөселманнар яшәгән ягына һичбер төрле хәвеф булмаган. Хәтта шәһәрнең бу өлешендәге мөселманнар 25 нче октябрьдә атышның кызу вакытында Кабан күле буена җыелып туп атуларын тамаша кылып тордылар, — дип язды «Кояш» газетасы[8].

Ә менә милли оешмаларның җитәкчеләре башланган атышларга битараф була алмыйлар. Алар моның зур ыгы-зыгыларга китерүенә шикләнмиләр. Чөнки солдат массаларына Н. Ершов, К. Грасис һәм дәүләт акчасын карта уйнап оттырганы өчен кулга алынып гауптвахтадан качып, солдатлар арасы-

на сыенган подпоручик Гроздов шикелле шикле кешеләрнең йогынтысы көчле була. Алар солдатларның сугышка каршы булган хисләрендә уйныйлар. Һәм инде, әлбәттә, очсыз популярлык яуларга өлгерәләр.

Боларның барысын да гарнизонда хезмәттә торган татар офицерлары бертуган Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар, Якуб Чанышев яхшы белгәннәр. Шунлыктан Бөтенроссия мөселман хәрби шурасы татар солдатларының вакыйгаларга катнашмавын тели. Татар солдатларының татар бистәләре иминлеген сакларга китүләре хуп күрелә.

Моны шушы газетаның 29 октябрь санында гарнизон мулласы яки ахуны Г. Баһаветдиневнең «24 октябрь төнендә» исемле мәкаләсеннән дә күрергә була. Мәкалә болай башлана: «Кич сәгать 7. Котлары очкан кешеләр төркеме узган-барган кешеләрне туктатып, яңа хәбәрләр сорашып, урам чатларында якты фонарь төпләрендә торалар. Күп кешеләр капкаларын ачып, акрын гына шәһәрдән читкә тынычлык эзләргә таялар. Кем кемгә, нәрсә өчен, кем өчен ата?» Нәкъ шуларны ачыклау максаты белән, автор, Бишбалтага 95-нче полк составындагы меңгә якын кешесе булган татар ротасына таба юл тота. Трамвай йөрмәгәнлектән, ул карт татар арбачысын күндереп, дамба аша аның арбасына утырып чыга. Ул егермеләп юнкерның дамба башында каравылда торганлыгын күрә. Ләкин алар мулланы, рәсми кеше булганлыгын күргәч, тоткарлап тормыйлар, үткәреп җибәрәләр. Бишбалтадагы хәлне Гатаулла хәзрәт болай тасвирлый: «Кап-караңгы. Бишбалта белән шәһәр арасында снаряд шартлаштыргалады. Әйтерсең, шәһәргә Кавказ халкы килгән. Әйтерсең, Бишбалтада немецлар да, шәһәрдә аларның дошманнары». Бу инде юнкерлар һәм солдатлар арасында башланып киткән бәрелешнең башлануын тасвирлау. Әлбәттә, ахун кешене кемнең кем белән сугышуы әллә ни кызыксындырмый. Ул башланган бәрелешне русларның үзара булган эчке эшләре һәм анда татарлар катнашырга тиеш түгел дип уйлый. Ул Бишбалтага татар солдатлары әллә кемнәр коткысына иярмәсеннәр, дип куркып бара. Һәм, чыннан да, куркуы юкка гына булмаган шул. Казармага барып керсә, ни күрсен: «Мөселман ротасындагы солдатларның кайсы иптәшләренә булышырга киткән, ә офицерлар канцелариядә математика мәсьәләсен хәл кылышып утыралар». Математик мәсьәлә дигәне шуннан гыйбарәт икән: шәһәр руслары бер-берсенә каршы атышалар, ә мөселман солдатларына нинди юл тотарга? Һәрберсе шул сорау белән аптыраган. Ахун исә татар солдатларын татар бистәсенә чыгарып, андагы татарларның иминлеген тәэмин итү күпкә кулай булыр дигән теләктә килгән була казармага. Ләкин солдатлар мулла абзыйларының сүзенә әлләни колак салмыйлар: имеш, алар татар бистәсенә китсә, рус солдатлары аларны юнкерларга сатылган дип уйлаулары ихтимал. Алай гына да түгел, төнге сәгать 12 дә алар башка хәрби частьларга вәкилләр җибәреп алардагы татар солдатларының да юнкерларга каршы фикердә икәнлеген ачыклагач, рус солдатлары белән гомуми полклар составында революция солдатларына кушылу турында карар кабул итәләр. Казандагы вакыйгалар турында Казаннан берәү, хәрби кеше булырга кирәк, хәрәкәттәге армиядәге бер газетага «гарнизонның күпчелеге ни өчен сугышканлыгын белми», — дип яза[9]. Икенче бер хәрбиләр чыгарган газетада Казандагы вакыйгалар турындагы хәбәрдә «образовался ревштаб во главе с юнцом прапорщиком Ершовым», — диелгән[10].

Татарларның Казандагы революцион вакыйгаларда катнашуын Хәрби Шура әгъзасы, солдатлар арасында кайнаган прапорщик С. Вәлидов болай тасвирлый: «Без, татарларның да, бик күп милли теләкләребез бар иде. Ләкин тарихлар буенча безнең каныбызга сеңеп килгән куркаклык, тарихи бер җебеклек безне шушы вакытларда украиннар артыннан барудан тыйды. Без һаман да үзебезнең теләкләребезне бар итәр өчен Иван Иванычларга йөгердек, аларның бусагаларын туздырдык. Билгеле, шуның аркасында безнең бер теләкләребез дә мәйданга килә алмады». Әлбәттә, бу сүзләрне язганда авторның революция көннәрендә татарларның милли аңлашу рәвешендә үз юлын таба алмавына үкенече сизелеп тора. Аның русларга карата бер нинди дошманлыгы юк, аларга карата бернинди дәгъва да белдерми, тик аларның һәммә сәяси партияләренең үз максатлары бар икәнлеген

генә инкарь итә. Ул татарларның бик күбесе «Барлык хакимиятне Советларга» дигән лозунгны яклап чыгуын да хата дип саный. Аны Советларның күпчелеге тик руслардан гына торган булуы борчый. «Тик руслардан гына гыйбарәт булган Советлар без — татар демократиясе өчен файдалы бик аз эш эшләр. Без, татарлар, хәзер үзебезгә генә ышанырга тиешбез, үз файдабызны тик үзебез генә үтиячәкбез. Шуңа күрә, без хәзердән соң үз арабыздагы бөтен ызгышларны ташлап эшкә керешергә, солдатлар белән эшчеләр бергә кушылып, үзебезгә бер мөселман солдат, эшчеләр һәм крестьяннар шурасы төзергә һәм шул килеш мөхтар татар дөньясының бөтен хакимиятен шуңа тапшырырга тиешбез». Әгәр бу шулай эшләнмәсә, без «милләт каршында зур җинаять кылган булырбыз», — дип саный автор. Аның бу фикеренә редколлегиядә каршы кешеләр булганлыктан, С. Вәлидов мәкаләсен тик шәхси фикере генә итеп белдерә. Бу аның үз фикере генә булмый, әлбәттә. Хәрби Шура җитәкчеләренең күпчелеге шундый карашта торган.


Аның шул ук газетаның, 8 ноябрь санында «Нинди юл белән бардык, хәзер нинди юл тотарга тиешбез?» исемле мәкаләсе дә кызыклы. Анда татар солдатларының большевиклар сүзен тыңлап, канлы вакыйгаларда катнашуларына әрнү белдерелә. Хәрби Шура бинасында милли оешмаларның гомуми җыелышында шураның рәисе И. Алкин җирле Советка, аның җитәкчеләренә карата шулай үзенең тискәре мөнәсәбәтен җиткерә. Ул, кайберәүләрдән аермалы буларак, Н. Ершовка һәм К. Грасиска ышанмый, аларны үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы карьеристлар итеп саный. Шунлыктан ул Советлар властен хуплау турындагы карарга каршы чыга. Ләкин күпчелек тарафыннан Совет властен яклауга өндәгән телеграммалар җибәрелә. Шулай итеп, җаваплы көннәрдә татарлар арасында бердәмлек булмый. 1918 елның январь аенда хәрби съездда ясаган докладында И. Алкин «октябрь көннәрендә шура кризис кичерде, чөнки аның мөселманнарны нейтралитетта калдыру мөмкинлеге булмады, һәм күпчелек басымы астында Совет властен котлау телеграммасы кабул ителде», — ди.

Ә шикләнүләр урынсыз булмый. 6 октябрь кичендә Дворяннар җыелышы бинасында Казан эшче, солдат һәм крестьян Советларының уртак киңәйтелгән утырышында яңа хакимият буларак Революцион штаб төзелгән вакытта И. Алкинның һәм С. Вәлидинең ни дәрәҗәдә хаклы икәнлекләре ачык күренә. Татарлар революциядә актив катнашкан һәм моны Н. Ершов үзе таныган булса да, 16 кешедән торган Революцион штабка бер генә татар да тәкъдим ителми. Тик Г. Баһаветдинов ялваруы аркасында гына анда И. Алкин, М. Вахитов һәм Ф. Туктаров кертеләләр. Бу, һичшиксез, татарлар белән санашырга теләмәүнең бер күренеше була. Күрәсең, Н. Ершов үзенең бер танышына җибәргән хатында Иван Грозныйдан соң Казанны беренче яулаучы булдым дип, юкка гына шапырынмагандыр. Революцион штаб эшли башлауга ук М. Вахитов һәм К. Грасис арасында зур каршылык чыгуы да юкка гына булмагандыр. Бу кеше инде үзен әллә кемгә куеп, русларның да бик күбесе белән бозылышып беткән була. Нәтиҗәдә, 3 ноябрь көнне Ревштаб үз вәкаләтләрен Совет кулына тапшыра. Ә К. Грасис һәм Н. Ершов Казаннан китәргә үк мәҗбүр булалар.

Бу — Казандагы Октябрь мизгелләре. Тик башка урыннарда да татарлар большевиклар яклы булалар. Хәтта Мәскәү һәм Петербургта да шул ук күренеш: татар солдатлары алар ягында. Мәскәүдә Милли Шура «бер уч Мәскәү татары» вакыйгаларга үзгәреш кертә алмас, диеп, аларны читтә калдырырга тырышса да, бу барып чыкмый. Петербургта власть Советлар кулына күчеп, аларга каршы Керенский-Краснов фетнәсе купкач, җирле Милли Шура татар солдатларын мәчет эченә кереп, фетнә үткәнне шуннан гына күзәтергә өндәсә дә, солдатлар моңа: «Үлсәк үләбез, Керенскийны Питерга кертмибез», — дип җавап бирәләр. Унынчы армия татарлары да Советлар властен бөтен көчләре белән яклаячакларын белдергән карар кабул итәләр[11].

Россиянең башка урыннарында да татарлар зур активлык күрсәтәләр. Сембер губернасының Сызрань шәһәрендә җирле советның рәисе итеп Ш. Усманов сайланган була. Петроградтан Советлар власте җиңүе турындагы хәбәр килүгә

үк шушы Совет үзен вәкаләтле җирле хакимият итеп белдерә. Ш. Усманов Акчуриннарның Гурьев фабрикасында кызыл гвардия отряды төзи. Сызрань шәһәр башлыгын кулга алгач җирле буржуазия Ш. Усмановтан аны җибәрүне таләп итә. Усманов исә аларга «юк» дип җавап бирә. Ә Сембернең үзендә Совет власте тик 1918 елның апрелендә генә урнаша. Монда да татарларның өлеше шактый була. Татар большевиклары Гафуров һәм Гайнуллин җитәкчелегендә үткәрелгән бер митингта татар кызылгвардиячеләре Советлар хакимиятен соңгы тамчы каннарына кадәр якларга ант итәләр һәм, чыннан да, шушы власть өчен үзләрен аямыйча көрәшәләр.



1917 елның май-июль айларында РСДРП(б)ның Казан комитеты урнашкан Рыбнорядская урамындагы 29 нчы йорт. Татарстан республикасы тарихи-сәяси документлар үзәк дәүләт архивы, фотодокументлар коллекциясе, инв. № 4638.

Әстерханда Совет властен урнаштыру өчен көрәш кораллы төс ала. Монда 7-нче мөселман ротасы большевикларның төп терәгенә әверелә. Җирле Шура җитәкчеләре Н. Гасрый һәм Г. Гомәров солдатларны казакларга каршы чыкмаска өндәсәләр дә, алар казаклар һөҗүмен кире кагып, шәһәр Кремлен үз кулларына төшерәләр. Алар янына акрынлап башка революцион көчләр туплана. 1918 елның 16-17 гыйнварында монда татар һәм казаклардан торган кызыл гвардия отрядлары килеп кушыла. 15-23 гыйнварь көннәрендә казаклар зур югалтуларга дучар булалар. 25 гыйнвар көнне алар, гомумән, шәһәрдән качалар. Соңрак саннары 3 меңгә җиткән татар ротасындагы солдатлар Кызыл армия сафларына кушылып, гражданнар сугышы вакытында Әстерханны аклардан саклауга зур өлеш кертәләр.

Октябрь көннәренә Уфадагы 144 полк мөселманлашкан һәм җирле революцион көчләр карамагына күчкән була. Уфаның үзендә Совет власте кан коюсыз тыныч ысул белән урнаша.

Декабрь ахырында Оренбургка Уфадан атаман Дутовка каршы сугышта большевикларга ярдәмгә 9 мең солдаттан торган мөселман полкы килеп җитә. Башка җирләрдән дә килгән революцион көчләр белән берлектә 16 гыйнвар көнне Дутов Оренбургтан куыла.

Татарларның революциядә катнашуларына караган бик күп башка фактларга да тукталып булыр иде. Аларның күбесе, шул исәптән хәрәкәттәге армиядәге хәлләрне төсмерләгәннәре дә, революциядә татар факторының шактый зур булуын раслый.

Ләкин татарлар тик большевикларны, революцияне генә якламаганнар, алар контрреволюция ягында да булганнар. Әйтеп үтелгәнчә, Казанда большевикларга каршы көчләр шактый була. Алар Ильяс һәм Җиһангир Алкиннар җитәкләгән Хәрби Шура тирәсендә тупланалар һәм соңрак Идел-Урал республикасын тормышка ашыру юнәлешендә шактый күп эш башкаралар.

Күп җирләрдә Милли Шура җитәкчеләренең революциягә каршы икәнлекләрен әйтеп үткән идек инде. Уфа, Оренбург, Әстерхан, Мәскәү, Петроград шәһәрләрендәге шуралар Совет хакимияте урнашуга ачыктан-ачык тискәре карашларын белдерәләр. Кадет С. Максуди, эсер Г. Исхакый социал-демократ

И. Әхтәмов һәм тагын шактый сандагы татар зыялылары Октябрь революциясен танымыйлар, Советларга каршы зур эш алып баралар.

Мөселман социалистлары комитеты рәисе булган М. Вахитов Совет хөкүмәтенә кертелеп, анда Эчке Русия мөселманнары комиссариатын җитәкли. Аның урынбасарлары итеп Г. Ибраһимов һәм Башкортшурасырәисе Ш. Манатов билгеләнә. М. Вахитов аклар Казанны алгач, алар кулына эләгеп, билгесез шартларда үтерелә. Г. Ибраһимов һәм Ш. Манатов шәхес культы корбаннары булалар.

Бу очракта Россиянең бик күп күренекле шәхесләре большевиклар белән баруны вакытлы хәл итеп кенә караганлыгын искәртеп китәргә кирәк. Аларның шактые вакыты җиткәч үз юллары белән киткәннәр. Әйтик, Польша социалистларының иң күренеклесе Ю. Пилсудский «мин социалистик поезддан бәйсезлек тукталышында төшеп калдым», дип язган. Димәк, мондый шәхесләр өчен социалистик юнәлеш бәйсезлеккә ирешү юлы итеп кенә каралган. Татар большевигы К. Якуб «без большевик булсак та, татарбыз», — дип әйтә торган булган һәм һәрвакыт милилекне беренче урынга куя килгән.

Тик менә татар большевикларының күбесе большевистик поезддан сикереп төшә алмый калалар. Чөнки поезд әле татар бәйсезлеге тукталышына барып җитмәгән була. Ә инде җитте дигәндә, сикереп төшеп калу мөмкинлеге юкка чыга. М. Солтангалиев шундыйлардан. 1922 елда СССР төзелгән вакытта ул бөтен көчен Татарстанны союздаш республика итүгә куя. Алай гына да түгел, СССР составында төрки республикар федерациясен булдыруны алга сөрә. Ләкин 1923 елны кулга алынып, партиядән чыгарыла, эшеннән азат ителә. Соңрак шәхес культы корбаны була.

Әдәбиятта татарларны бер-берсенә каршы куеп, аларның берәүләрен халык дошманнары, икенчеләрен аның бәхете өчен көрәшүчеләр итеп күрсәтү традициягә әверелгән иде. Тик мондый караш дөреслеккә туры килми. Аларның барысы да халык бәхете өчен көрәшкән милләтпәрвәрләр. Аерма шунда гына, алар үз юлларын милли гаделлеккә, татар мәнфәгатьләрен тормышка ашырырдай бердәнбер дөрес юл дип санаганнар. Һ. Атласи аларны юкка гына дус-дошманнар дип атамагандыр.

Татарларның большевикларга һәм Совет властена баглаган өметләре, нигездә, акланмый. Дөрес, революция нәтиҗәсендә Татарстан автономияле республикасы барлыкка килә һәм соңрак шуңа таянып суверен дәүләт өчен көрәш җәелдерү мөмкинлеге туа. Ләкин югалтулар да күп була бит. Татарның дине бетте, теле юкка чыга язды, үзе әле бүген дә ассимиляциягә эләккән рәвештә яши. Аның яңарышын тәэмин итү искиткеч авыр эшләрнең берсе булып тора.

Шулай да, үткән тарих, нинди генә булмасын, ул — безнең тарих. Без бүген милләтпәвәрләребезнең кызыллар ягындамы, аклар ягындамы булуларына карап бәяләргә тиеш түгелбез. Чөнки аларның күбесе теләсә кайсы очракта да беренче урынга шәхси мәнфәгатьләрен түгел, ә милләт алдындагы бурычларны куя алган.

Революция — ул искиткеч катлаулы процесс. Ул аклы-каралы гына түгел. Анда салават күперенең барлык төсләре дә бар. Әле безнең аларны күреп һәм аңлап бетерә алганыбыз юк. Монысы безнең киләчәк фәнни бурычларыбызның иң әһәмиятлеләреннән.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Корылтай. – 1917. – 2 июль.
2. Шунда ук.
3. Шунда ук.
4. Шунда ук. – 14 июль.
5. Шунда ук.
6. Безнең тавыш. – 1917. – 24 октябрь.
7. Шунда ук. – 8 ноябрь.
8. Кояш. – 1917. – 29 октябрь.
9. Голос III армии. – 1917. – 31 октября.
10. Известия фронтового отдела «Румчерод». – 1917. – 16 ноября.
11. Воин-гражданин. – 1917. – 29 декабря.

Индус Таһиров,
тарих фәннәре докторы

№ 1. Из сообщения в «Казанской рабочей газете» об объединенном заседании Совета рабочих, солдатских и крестьянских депутатов

7 сентября 1917 г.

Зал заседания (Дворянское собрание) переполнен. На повестке дня вопрос о кризисе власти и о посылке делегата на демократическое совещание в Петроград. Председательствует Колегаев*. Первым выступал тов. Вегер** (с[оциал]-д[емократ]). Докладчик, говоря о власти, отмечает, что власть была в стороне от организованной демократии (Советы) и поэтому была бессильна, она не удовлетворяла даже буржуазию. Кадеты на Московском совещании требовали буржуазного кабинета, а выступление Корнилова имело своей целью совершенное уничтожение демократических организаций. Но, говорит далее Вегер: «О социализме и его осуществлении теперь может говорить только сумасшедший или провокатор». По мнению Вегера, Временное правительство должно опереться на революционные народные организации. Созываемое в Петрограде демократическое совещание должно превратиться в революционный парламент, заседающий впредь до Учредительного собрания, а Временное правительство должно быть ответственным пред этим парламентом. От фракции большевиков выступает Бернгейм***. Он передает привет от 12 000 рабочих Сормовского завода, которые выражают надежду, что Казанский совет также встанет на славный революционный путь Петроградского совета. Докладчик, критикуя Временное правительство партии «Народная свобода», а потом коалиционное Временное правительство «социалистических» партий (меньшевики, эсеры), приходит к выводу, что во Временном правительстве не должно быть представителей ни крупной, ни мелкой буржуазии. Вся власть должна перейти в руки пролетариата и беднейшего крестьянства. Временное правительство должно быть выбрано демократическим совещанием, и мы должны дать своим делегатам следующие директивы (читает резолюцию, предложенную фракцией большевиков). «Перед лицом контрреволюционно-изменнического выступления генерала Корнилова, подготовленного и поддержанного партиями и группами, представители которых входят в состав Временного правительства во главе с партией кадетов, Казанский совет солдатских и рабочих депутатов считает нужным провозгласить, что отныне должно быть решительно прекращено всякое колебание в деле организации власти. От власти должны быть отстранены не только представители кадетской партии, открыто замешанные в изменническом выступлении, и представители цензовых элементов вообще, но должна быть в корне изменена и вся та политика соглашательства и безответственности, которая создала самую возможность превращения верховного командования из аппарата государственной власти в очаг и орудие заговора протии революции. Не терпимы далее ни исключительные полномочия Временного правительства, ни его безответственность. Единственный выход — это создание решительной власти революционного пролетариата и крестьянства, в основу деятельности которой и должно быть положено следующее: 1) декретирование Демократической республики; 2) немедленная отмена частной собственности на все земли и инвентарь, без выкупа, и передача их в заведывание крестьянских комитетов впредь до решения Учредительного собрания; 3) введение рабочего контроля над производством и распределением в общегосударственном масштабе; 4) национализация важнейших отраслей промышленности; 5) беспощадное обложение крупных капиталов и имуществ и конфискация военной прибыли в целях спасения страны от хозяйственной разрухи; 6) объявление тайных договоров недействительными; 7) немедленное предложение всем воюющим народам демократического мира. В качестве немедленных мер должно быть декретировано: 1) прекращение всяких репрессий, направленных против рабочего класса и его организаций; 2) немедленная отмена смертной казни на фронте и восстановление полной свободы агитации для всех демократических организаций армии, очищение ее от контрреволюционного состава, выборность

---

* Колегаев А. Л. (1887-1937), один из лидеров партии левых эсеров. В 1917 г. — председатель Казанского совета крестьянских депутатов, член ЦК и руководитель Казанского комитета партии эсеров, редактор газеты «За землю и волю». С декабря 1917 г. по март 1918 г. — Нарком земледелия РСФСР, затем член РВС Южного фронта, коллегии наркома путей сообщения. С 1921 г. на административно-хозяйственной работе. Репрессирован, реабилитирован посмертно (здесь и далее подстрочные примечания Г. Фаезовой и С. Елизаровой).

** Вегер В. И. (1888-1945), участник революционного движения и Гражданской войны, партийный работник, ученый.

*** Бернгейм Л. М. (Бакинский С. С.) (1886-?), член Казанского комитета РСДРП, в 1917 г. — представитель Московского областного бюро РСДРП(б) в Казани.

комиссаров местными организациями; 3) осуществление на деле прав[а] наций, живущих в России, на самоопределение, т. е. в первую очередь удовлетворение требований Финляндии и Украины; 4) роспуск Государственного совета и Государственной думы и 5) немедленный созыв Учредительного собрания» (сильные аплодисменты). От имени эсеров выступает Колегаев, который говорит, что коалиционное правительство занималось соглашательством с буржуазией и вредило народу. Организованная буржуазия (кадеты) не должна быть у власти. Созыв демократического совещания необходим, так как одно лицо, Керенский, не может образовать правительство. В заключение он предлагает резолюцию, в которой указывается на стремление буржуазии взять власть в свои руки и закрепить революцию только в рамках политического переворота, тогда как революционная демократия расширяет свои завоевания в области социального переустройства. Создание правительства из буржуазных элементов вредно отзывается на демократии. Далее в резолюции говорится, что вопрос о правительстве должен быть разрешен на демократическом совещании и что новое Временное правительство должно работать в полном контакте с Советами и быть ответственным перед ними, а также в основу своей деятельности должно положить постановления Всероссийских Советов о земле, войне, рабочем законодательстве, политическом и национальном устройстве. Находит необходимым прекращение дел по аграрным преступлениям, преследование за левое течение социалистической мысли, отмену смертной казни, упразднение Государственной думы и Государственного совета и создание революционных штабов при всех военных управлениях. Другой путь устранения правительственного кризиса помимо созыва совещания считается невозможным. Далее выступает д[окто]р Шергов (меньшевик-оборонец), который заявляет, что идея коалиции не только не опровергнута, но остается жизненной и по сей день. Корниловский заговор был ликвидирован только благодаря единодушию демократии, которая встала на защиту Временного правительства. Объективно контрреволюция опирается на тяжелые экономические условия и темноту и несознательность масс. Субъективно же классы помещиков и буржуазии пользуются этим для закрепления своего политического господства над демократией. Демократия не представляет однородной массы и не станет поэтому поддерживать лозунг: «Вся власть Советам депутатов». На Московском демократическом совещании собралось воедино все живое, все дееспособное, все творческое в рядах демократии. Предстоящее совещание не может пройти мимо платформы демократии Московского совещания и на вопрос о коалиции не может ответить категорически «нет». Читает резолюцию кооператоров об их отношении к демократическому совещанию. Совет кооперативных съездов, Центральный союз потребительских обществ, Московский народный банк, Центральное товарищество льноводов и Сибирский союз маслодельных артелей заявляют о необходимости превратить демократическое совещание в общенациональное и сохранить начала коалиции при образовании власти. Большевики предлагают их просто скостить со счетов демократии. Кроме того, в совещании примут участие городские самоуправления, которые ни в коем случае не станут поддерживать губительный для революции лозунг большевиков «Вся власть Советам». Если же идея коалиции будет отвергнута и лозунги большевизма восторжествуют, то это будет означать полный крах революции. Вне коалиции нет выхода для государства из того ужасного, почти безвыходного тупика, в котором оно очутилось…

№ 2. Сообщение в газете «За землю и волю» о собрании городской организации партии социалистов-революционеров

31 октября 1917 г.

Общее собрание городской организации партии с[оциалистов]-р[еволюционеров], обсудив вопрос о текущем моменте, приняло следующую резолюцию: 1). Признать совершившийся в России переворот актом революционным. 2). Единственным выходом из создавшегося положения признать переход власти к Советам. 3). Первейшей задачей новой власти признать немедленный созыв Учредительного собрания. 4). Признать, что восстановление власти Временного правительства в настоящее время было бы началом контрреволюции. 5). Констатировать, что в Казани власть к Советам не перешла, а захвачена безответственными лицами. 6). Организовать Совет рабочих солдатских и крес-

тьянских депутатов таким образом, чтобы он мог фактически взять в свои руки власть и освободить город и губернии от демагогии отдельных личностей. 7). Работать со всей энергией в Советах и активных работников с их постов не отзывать. 8). В революционный штаб, до его реконструкции на демократических началах, делегатов не посылать. 9). Немедленно взять в свои руки совместно с Советом крестьянских депутатов дела губернского комиссариата.

№ 3. Обращение Казанского революционного штаба к гражданам г. Казани и губернии

31 октября 1917 г.

Кошмарные дни борьбы миновали. Революционные войска победили. Этой победой власть передана народу в лице его полномочных органов — Советов рабочих, солдатских и крестьянских депутатов. Не только в Казани свергнута власть буржуазии, капиталистов и помещиков, но и в Петрограде и еще в ряде других городов. Это не значит, что борьба с буржуазией [о]кончена. Борьба продолжается и продолжится до тех пор, пока не установится и не утвердится окончательно народовластие. Победители будут поэтому бдительны. Казанский революционный штаб, выбранный Советом рабочих, солдатских и крестьянских депутатов совместно с войсковыми организациями, заводскими комитетами и представителями социалистических партий, принимает все меры, чтобы предотвратить внешнюю опасность, т. е. нашествие послушных буржуазному правительству войск. Это с одной стороны. С другой — стороны в городе Казани устанавливается строгий революционный порядок, никакие беспорядки и эксцессы не будут допустимы. К товарищам — рабочим и солдатам обращаемся с предостережением: не поддавайтесь на провокацию. Вас будут смущать и возмущать те, чья власть сломана, проходите мимо их с презрительным хладнокровием. Власть перешла народу. Высший орган управления — Совет рабочих, солдатских и крестьянских депутатов. Отныне народ сам будет творить свою жизнь, решать свою судьбу. Иначе и быть не может: только сам народ выведет себя из того трудного положения, в какое его ввергли буржуазные управители-опекуны. Мы глубоко убеждены, что в народе достаточно творческих сил, чтобы создать себе светлое будущее без гнета, без слез и без страданий. Казанский революционный штаб призывает всех оказать должную поддержку народной власти — больше взаимного доверия и больше сотрудничества. Казанский революционный штаб ставит в известность население, что начальником Казанского гарнизона избран штабс-капитан Масальский, один из главных руководителей восставших войск. Временно до окружного съезда Советов солдатских депутатов командующим войсками избран прапорщик Ершов, помощником его — полковник Руанет, начальником милиции г. Казани избран Бухов. Должности комиссаров (губернских и уездных) упраздняются и их дела и кредиты передаются в Советы крестьянских депутатов. Все остальные должностные лица, пока они не заменены новыми, должны исполнять свои обязанности. Попустительств быть не должно. Они в данный момент преступней, чем когда бы то ни было, и виновные будут преданы революционному суду.

Грачев Е. Казанский Октябрь. Хроника революции 1917 г. – Казань, 1926. – С. 162-165, 226-228.

Подборка документов
Гузель Фаезовой,
начальника отдела использования и публикации документов ЦГА ИПД РТ,
Софьи Елизаровой,
главного специалиста ЦГА ИПД РТ

РЕЗЮМЕ
В публикации И. Тагирова анализируются октябрьские события 1917 г. Особое внимание уделяется участию в них татар. Участие это было не простым, ибо немало татар находилось по обе стороны баррикад. Автор пытается дать свое объяснение этому феномену. В статье использованы, главным образом, материалы татарских газет и документы архивов России и Татарстана.